ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.10.2022 п.г.т.Алексеевское № 445

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль берәмлекләре башлыкларының,муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының,депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы әгъзаларының, рәисләрнең, рәисләрнең урынбасарларының,муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләмен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларының күләмнәрен арттыру турында**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, рәисләрнең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларының күләмнәрен арттыру турында»22.08.2022 ел № 881 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 17.04.2018 № 36 «Депутатларның , үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» гы карары белән расланган муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, рәисләрнең,

рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 17.04.2018 № 36 «Депутатларның , үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» гы карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең үзләре биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфа окладлары күләмен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазифа оклады күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Бу карар имзаланган көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен финанс-бюджет палатасы Рәисе О.Н.Леденцовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**